ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«_05_» ___04_______ 2019 г. № __2__

Устав фондын арттыруга “Урыссу
төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча
предприятиесе” муниципаль унитар
предприятиесенә субсидия бүлеп бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2018 елның 17 декабрендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының «2019 елга һәм 2020-2021 еллардагы планлы чорга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе бюджеты турында» карары нигезендә, Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Башкарма комитетының 2019 елның 3 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль унитар предприятиеләргә устав фондын арттыруга субсидияләр бүлеп бирү тәртибен раслау турында”гы карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге бюджетыннан «Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча Урыссу предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесенә, субсидия бирү турында килешүгә кул куйганнан соң өч банк көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы Казначылык Департаментының территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерү юлы белән, устав фондын арттыруга 12 000 000 (унике миллион) сум күләмендә субсидия бүлеп бирергә .

2. Әлеге боерык кабул ителгән көннән соң өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге бюджетыннан устав фондын арттыруга муниципаль унитар предприятиеләргә субсидияләр бирү Тәртибенә №1 кушымта ярашлы килешү төзергә.

3. Әлеге боерыкны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.З. Гыйбадуллина